ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.08.2018 г. Заинск № 1325

**«ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 08.12.2017 ел №2252 «Зәй шәһәреннән 11 километрдан читтә урнашкан ерак һәм халык саны аз булган авыл нокталарына беренче кирәк-ярак товарлары китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгым өлешләрен кайтаруга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр тәкъдим итү Тәртибен раслау турында»**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 маддәсе нигезендә 31.07.1998 №145-ФЗ, Зәй муниципаль районы Уставының 45 нче маддәсенә таянып, ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карары:**

1. 1 нче кушымтаның 1.1 пункты 08.12.2017 ел №2252 ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты «Зәй шәһәреннән 11 километрданераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авыл нокталарына беренче кирәк-ярак товарлары китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгым өлешләрен кайтаруга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр тәкъдим итү Тәртибен раслау турында» карарын түбәндәге редакциядә язарга:

«1.1. Әлеге Карар агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив-хокукый акты билгеләгән күләмдә Зәй муниципаль районы бюджетына бүлеп бирелгән чаралар хисабына субсидияләр тәкъдим итү, Зәй шәһәреннән 11 километрдан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авыл нокталарына беренче кирәк-ярак товарлары китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгым өлешләрен кайтару тәртибен урнаштыра».

2. пункт 1.1. Зәй муниципаль районы бюджетыннан булган чыгым өлешләрен кайтаруга субсидияләр тәкъдим итү турындагы килешүләрне түбәндәге редакциядә язарга:

«1.1. Килешү предметы булып Зәй шәһәреннән 11 километрдан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авыл нокталарына беренче кирәк-ярак товарлары китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгым өлешләрен кайтару тора. Зәй районы Башкарма комитеты агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив-хокукый акты билгеләгән күләмдә Зәй муниципаль районы бюджетына бүлеп бирелгән чаралар хисабына субсидияләр тәкъдим итә».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны районның икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә һәм эшкуарлыкка ярдәм итү буенча Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары П.А.Байрашевка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**

М.М.Хабибуллин
885558 3-13-37